**Татарстан Республикасы**
**Әлки муниципаль районы**
**Чуаш Борнае авыл Советы**
**КАРАРЫ.**

**2018 нче елның 30 нчы ноябреннән** **29 №**

**ФИЗИК ЗАТЛАРНЫҢ МИЛКЕНӘ САЛЫМ ТУРЫНДА**

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге, 2014 елның 30 октябрендәге 82-ТРЗ номерлы “Татарстан Республикасы территориясендә физик затлар мөлкәтенә салым буенча салым базасын салым салу объектларының кадастр бәясеннән чыгып билгеләү тәртибен” Татарстан Республикасы Законы нигезендә Әлки муниципаль районы Чуаш Борнае авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

**1.Әлки муниципаль районы Чуаш Борнае авыл җирлеге Советы территориясендә мәҗбүри түләнергә тиешле физик затлар милкенә салым билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.**

**2. Салым ставкаларын күләмен билгеләргә:**

1) 0,1 процент карата:

мәйданы 50 квадрат метрдан артмаган һәм шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, дача хуҗалыгы, яшелчәчелек, бакчачылык яки шәхси торак төзелеше өчен бирелгән җир участокларында урнашкан хуҗалык корылмалары яки корылмалары;

"мәйданы 30 квадрат метрдан артмаган һәм Россия Федерациясе Салым кодексының 3782 статьясындагы 7 пункты нигезендә билгеләнә торган исемлеккә кертелгән салым салу объектларында, шулай ук Россия Федерациясе Салым кодексының 3782 статьясындагы 10 пунктының икенче абзацында каралган салым салу объектында урнашкан гаражлар һәм машина-урыннар.

Ставкасы салым түләүчене сайлау буенча бер гараж яки машина урынына карата билгеләнә”;

2) 0,2 процент карата:

бүлмә; фатирларның бер өлеше;

3) 0,3 процент карата:

торак йортлар; торак йортларның бер өлеше;

ике фатирдан торган күпфатирлы бер катлы торак йорттагы фатир;

торак йорт буларак проектланган, төзелеп бетмәгән объектлар;

составына бер генә торак йорт керә торган бердәм күчемсез комплекс;

4) 2 процент карата:

Россия Федерациясе Салым кодексының 3782 статьясындагы 7 пункты нигезендә билгеләнә торган исемлеккә кертелгән салым салу объектлары;

Россия Федерациясе Салым кодексының 3782 статьясындагы 10 пунктының икенче абзацында каралган салым салу объектларына карата;

5) 2 процент карата:

кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып киткән салым салу объектлары;

6) 0,5 процент салым салуның башка объектларына карата.

7)ике фатирдан торган күпфатирлы бер катлы торак йорттагы фатирга милек хокукы булган физик затларга әлеге фатирның гомуми мәйданының кадастр бәясендәге салым ставкасының процент өлеше буларак билгеләнә торган суммага исәпләнгән салым суммасын киметү рәвешендәге ташламаны билгеләргә.

Әгәр фатир гомуми өлешле милектә булса, ташламалар суммасы өлешләп милектәге һәр кеше өчен аның бу фатирга милек хокукындагы өлешенә пропорциональ рәвештә исәпләнә.

Әгәр фатир уртак милектә булса, ташламалар суммасы уртак милектә катнашучыларның һәркайсы өчен тигез өлешләрдә исәпләнә.

Шул ук вакытта әлеге пункт нигезендә исәпләнгән ташламалар суммасы, исәпләнгән салым суммасыннан артып китә алмый”.

**3. Физик затларны милкенә салым түләүдән азат итү:**

1. 18 яшькә кадәрге биш һәм аннан да күбрәк балалары булган салым түләүчеләр;
2. әлеге пунктның 1 пунктында күрсәтелгән салым түләүчеләрнең балалары.

**4.Үз көчен югалткан дип танырга:**

Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Чуаш Борнае авыл җирлеге Советының 2015 елның 8 маендагы “Физик затлар милкенә салымнар турында"гы 16 номерлы карарын; Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Чуаш Борнае авыл җирлеге Советының 2015 елның 12 октябрендәге 5 номерлы “Чуаш Борнае авыл җирлеге Советының 2015 елның 8 маендагы 16 номерлы “Физик затларның милкенә салым турында" карарына үзгәрешләр кертү турында" карарын; Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Чуаш Борнае авыл җирлеге Советының 2018 елның 31 маендагы 10 номерлы карары «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Чуаш Борнае авыл җирлеге Советының 2015 елның 8 маендагы 16 номерлы “Физик затлар милкенә салымнар турында" карарына үзгәрешләр кертү турында карарын; Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Чуаш Борнае авыл җирлеге Советының 2018 елның 24 августында кабул ителгән 18 номерлы «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Чуаш Борнае авыл җирлеге Советының 2018 елның 31 маенда кабул ителгән 10 номерлы «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Чуаш Борнае авыл җирлеге Советының 2015 елның 8 маендагы 16 номерлы “Физик затлар милкенә салым турында” карарына үзгәрешләр кертү турында" карарына үзгәрешләр кертү турында" карарын.

4. Әлеге карар 2019 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә, әмма рәсми басылып чыккан көненнән бер айдан да иртәрәк булмаган вакытта.

Әлки муниципаль районы
Чуаш Борнае авыл Советы Рәисе,
авыл җирлеге башлыгы — Зарипов И.Г.

Республика Татарстан Алькеевский муниципальный район Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Р.06-9280/15 СОВЕТ ЧУВАШСКО-БУРНАЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ОГРН 1021505757095 ИНН 1606000314 КПП 160601001